**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 29 сентябрь № 724

г. Казань

Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар тармагында контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 5 өлеш, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнарын булдыруга, раслауга һәм алып баруга таләпләр, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнары формасына таләпләр турында» 2013 ел, 21 ноябрь, 1043 нче карары нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар системасын камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына әлеге карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә әлеге карар белән расланган Тәртипне товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказларны урнаштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясенең рәсми сайтында (www.zakupki.gov.ru) урнаштырырга.

3. Җирле үзидарә органнарына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнарын булдыруга, раслауга һәм

алып баруга таләпләр, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнары формасына таләпләр турында» 2013 ел, 21 ноябрь, 1043 нче карары белән билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару тәртибен билгеләргә тәкъдим итәргә.

4. Бу карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\724.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 29 сентябрь, 724 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару**
**тәртибе**

1. Бу Тәртип «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар тармагында контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Контракт системасы турында закон) нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнарын булдыру, раслау һәм алып бару кагыйдәләрен (алга таба – сатып алулар планы) билгели.

2. Сатып алулар планнары эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә түбәндәгеләр тарафыннан раслана:

а) Татарстан Республикасы исеменнән эш иткән дәүләт заказчылары (алга таба – дәүләт заказчылары) тарафыннан – тиешле дәүләт заказчысына Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә йөкләмәләр кабул итүгә һәм (яки) үтәүгә акчалата булган хокуклар күләмен җиткергәннән соң;

б) Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан, Контракт системасы турында законның 15 статьясындагы 2 һәм 6 өлешләр нигезендә гамәлгә ашырылган сатып алулардан тыш – финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын раслаганнан соң;

в) Контракт системасы турында законның 15 статьясындагы 4 өлештә каралган очракта, мөлкәтләре милек хокукында Татарстан Республикасыныкы булган Татарстан Республикасы дәүләт автоном учреждениеләре, дәүләт унитар предприятиеләре тарафыннан – дәүләт милкен капиталь төзү объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга яки дәүләт милкенә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга субсидияләр (алга таба – капитал салуларга субсидияләр) бирү турында килешүләр төзегәннән соң. Бу очракта сатып алулар планына капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр исәбеннән планлаштырылган сатып алулар гына кертелә;

г) Контракт системасы турында законның 15 статьясындагы 6 өлештә каралган очракларда, үзләренә Татарстан Республикасы дәүләт органнары, территориаль дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнары тапшырган Татарстан Республикасы исеменнән күрсәтелгән органнар йөзендә дәүләт контрактларын төзү һәм үтәү буенча дәүләт заказчысы вәкаләтләре кысаларында сатып алуларны гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт бюджет, дәүләт автоном учреждениеләре, мөлкәтләре милек хокукында Татарстан Республикасыныкы булган дәүләт унитар предприятиеләр тарафыннан – тиешле исәп-хисап счетына тапшырылган вәкаләтләр буенча Россия Федерациясенең

бюджет законнары нигезендә йөкләмәләр кабул итүгә һәм (яки) үтәүгә акчалата булган хокуклар күләмен җиткергәннән соң.

3. Татарстан Республикасы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планнары әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән затлар тарафыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу тармагында төбәк мәгълүмат системасын (алга таба – ТМС) файдаланып, чираттагы финанс елына һәм планлаштырылган чорга (чираттагы финанс елы) түбәндәге нигезләмәләрне исәпкә алып формалаштырыла:

а) дәүләт заказчылары Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән төп эш итүчеләр, территориаль дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнары (алга таба – төп эш итүчеләр) билгеләгән вакытларда, әмма агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча:

Контракт системасы турында законның 13 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнгән сатып алуларны гамәлгә ашыру максатларыннан чыгып, сатып алулар планын формалаштыралар һәм аларны төп эш итүчеләргә алар нигезендә Россия Федерациясенең бюджет законнарына яраклы рәвештә сатып алуларны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләрен нигезләүләр формалаштыру өчен тапшыралар;

бюджет сметалары проектларын төзү һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында закон проектын төзегәндә Россия Федерациясенең бюджет законнарына яраклы рәвештә сатып алуларны гамәлгә ашыруга бюджет ассигнованиеләрен нигезләүләрне төп эш итүчеләргә тапшыру процессында төп эш итүчеләр белән килештереп, сатып алулары планнарын тәгаенлиләр;

кирәк булганда, формалаштырылган сатып алулар планнарын тәгаенлиләр, аларны тәгаенләгәннән һәм дәүләт заказчысына Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә йөкләмәләр кабул итүгә һәм (яки) үтәүгә акчалата булган хокуклар күләмен җиткергәннән соң, әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән вакытларда формалаштырылган сатып алулар планнарын раслыйлар һәм бу хакта төп бүлүчегә хәбәр итәләр;

б) әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән учреждениеләр аларның гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы органнар билгеләгән вакытларда, әмма агымдагы елның 1 июленнән соңга калмыйча:

Россия Федерациясе законнар нигезендә финанс-хуҗалык эшчәнлеген планлаштырганда сатып алулар планын формалаштыралар һәм Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә бюджет ассигнованиеләрен нигезләүләрне формалаштырганда исәпкә алу өчен аларның гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы органнарга тапшыралар;

кирәк булганда, аларның гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы органнар белән килештереп, аларның финанс-хуҗалык эшчәнлеге һәм Россия Федерациясенең бюджет законнарына яраклы рәвештә бюджет ассигнованиеләрен нигезләүләрне тапшыру планнары проектларын төзү процессында сатып алулар планнарын тәгаенлиләр;

кирәк булганда, сатып алулар планнарын тәгаенлиләр, аларны тәгаенләгәннән

һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын раслаганнан соң, әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән вакытларда формалаштырылган сатып алулар планнарын раслыйлар һәм бу хакта аларның гамәлгә куючысы вазыйфаларын һәм вәкаләтләрен башкаручы органнарга хәбәр итәләр;

в) әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «в» пунктчасында күрсәтелгән юридик затлар:

капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү турында карарлар кабул иткәннән (карарлар проектлары килештергәннән) соң, төп эш итүчеләр тарафыннан билгеләнгән вакытларда, әмма агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча, сатып алулар планнарын формалаштыралар;

кирәк булганда, сатып алулар планнарын төгаенлиләр, аларны тәгаенләгәннән һәм капитал салуларны гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү турында килешүләр төзегәннән соң, әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән вакытларда сатып алулар планнарын раслыйлар;

г) әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән юридик затлар:

Татарстан Республикасы дәүләт милкен капиталь төзү объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру яки Татарстан Республикасы дәүләт милкенә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алу турында карарлар кабул иткәннән (карарлар проектлары килештергәннән) соң, төп эш итүчеләр билгеләгән вакытларда, әмма агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча, сатып алулар планнарын формалаштыралар;

кирәк булганда, сатып алулар планнарын төгаенлиләр, аларны тәгаенләгәннән һәм дәүләт заказчысына Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә йөкләмәләр кабул итүгә һәм (яки) үтәүгә акчалата булган хокуклар күләмен җиткергәннән соң, әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән вакытларда сатып алулар планнарын раслыйлар.

4. Чираттагы финанс елына һәм планлаштырылган чорга сатып алулар планы расланган сатып алулар планының чираттагы елы һәм планлаштырылган чорның беренче елы параметрларына үзгәрешләр кертү һәм аларга планлаштырылган чорның икенче елы параметрларын өстәү юлы белән эшләнә.

5. Сатып алулар планы Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы, территориаль дәүләт бюджеттан тыш фонд бюджеты турында Татарстан Республикасы законы төзелгән вакытка формалаша.

6. Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә дәүләт заказчыларының сатып алулар планнарына, шулай ук әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән юридик затларның сатып алулар планнарына планлаштыру чоры дәвамында гамәлгә ашыру планлаштырылган сатып алулар турында мәгълүмат кертелә. Бу очракта мәгълүмат планлаштырылган сатып алуларның бөтен вакытына сатып алулар планына кертелә.

7. Әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән затлар Контракт системасы турында закон һәм әлеге Тәртип нигезләмәләре нигезендә сатып алулар планнарын алып баралар. Кирәк булган очракта расланган сатып алулар планнарына үзгәрешләр кертү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

а) сатып алулар планнарын Контракт системасы турында законның 13 статьясы нигезләмәләрен исәпкә алып билгеләнгән сатып алуларны гамәлгә ашыру максатларындагы расланган үзгәрешләргә һәм Контракт системасы турында законның 19 статьясы нигезендә урнаштырылган сатып алына торган товарларга, эшләргә, хезмәтләргә (шул исәптән товарлар, эшләр, хезмәтләрнең чик бәясенә) карата таләпләргә һәм сатып алуларны гамәлгә ашыру максатлары һәм дәүләт органнарының һәм алар ведомствосындагы казна учреждениеләренең, территориаль дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнарының вазыйфаларын тәэмин итүгә норматив чыгымнарга яраштыру;

б) сатып алулар планнарын агымдагы финанс елына (агымдагы финанс елы һәм планлаштырылган чор) Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законына, территориаль дәүләт бюджеттан тыш фонд бюджеты турында законга үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законына яраштыру;

в) сатып алулар планнарын раслаганнан соң кабул ителгән һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында закон белән расланган бюджет ассигнованиеләре күләме үзгәрүгә китермәгән федераль законнарны, Россия Федерациясе Президенты карарларын, йөкләмәләрен, күрсәтмәләрен, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларын, йөкләмәләрен, Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын, йөкләмәләрен гамәлгә ашыру;

г) сатып алулар турында мәҗбүри җәмәгатьчелек фикер алышуы йомгаклары буенча дәүләт заказчысы яки юридик зат кабул иткән карарны тормышка ашыру;

д) сатып алуларны тормышка ашырганда алынган файданы Россия Федерациясе законнары нигезендә куллану;

е) Контракт системасы турында законның 19 статьясы нигезендә билгеләнгән тикшерүдә тоту органнары тарафыннан күрсәтмә бирү, шул исәптән алып килеп бирүчеләрне (подрядчыларны, үтәүчеләрне) билгеләү процедурасын гамәлдән чыгару турында.

8. Сатып алулар планына Контракт системасы турында законда билгеләнгән очракларда чираттагы финанс елында һәм (яки) планлаштырылган чорда гамәлгә ашырылулары турында белдерү урнаштырырга планлаштырылган яисә алып килеп бирүчеләрен (подрядчыларын, үтәүчеләрен) билгеләүдә катнашырга чакыру җибәрергә планлаштырылган сатып алулар турында мәгълүмат, шулай ук күрсәтелгән чорда контрактлар төзү планлаштырылган бердәнбер алып килеп бирүченең (подрядчының, үтәүченең) сатып алулары турында мәгълүмат кертелә.

9. Әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән юридик затлар тарафыннан сатып алулар планнарын формалаштыру, раслау һәм алып бару әлеге затларга дәүләт заказчысы вәкаләтләрен тапшырган тиешле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, территориаль дәүләт бюджеттан тыш фондлар белән идарә итү органнары йөзеннән гамәлгә ашырыла.

10. Расланган сатып алулар планы мондый план расланган яки үзгәргән көннән соң эш көннәрендә исәпләнелгән өч көн эчендә, дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләрдән тыш, ТМС файдаланып, бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.

11. Сатып алулар планы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнарын булдыруга, раслауга һәм алып баруга таләпләр, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар планнары формасына таләпләр турында» 2013 ел, 21 ноябрь, 1043 нче карары белән расланган форма буенча эшләнә.